# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

"Татарстан Республикасы халык депутатларының
җирле Советлары халык депутатлары статусы
турында" Татарстан Республикасы Законына
үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында

1 статья. "Татарстан Республикасы халык депутатларының җирле Советлары халык депутатлары статусы турында" 1990 елның 14 декабрендәге Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Югары Советы җыелма басмасы, 1992, N 1) үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә, аны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Татарстан Республикасы халык депутатларының
җирле Советы халык депутаты статусы турында

Татарстан Республикасы
З А К О Н Ы

Татарстан Республикасы халык депутатларының җирле Советы халык депутаты Татарстан Республикасы җирле Советы территориясендә дәүләт хакимияте вәкиле булып тора.

Җирле Совет халык депутаты үз эшчәнлегендә Татарстан Республикасы Конституциясенә һәм законнарына, җирле Совет карарларына, тиешле район, шәһәр, шәһәрдәге район һәм үзе сайланган сайлау округы халкы мәнфәгатьләренә таянып эш итә.

## I бүлек

## Гомуми нигезләмәләр

1 статья. Татарстан Республикасы халык депутатларының җирле Советы халык депутаты статусы турында законнар

Татарстан Республикасы халык депутатларының җирле Советы халык депутатының статусы Татарстан Республикасы Конституциясе, "Дәүләт хакимиятенең һәм идарәсенең җирле органнары турында" Татарстан Республикасы Законы, әлеге Закон һәм Татарстан Республикасының башка закон актлары тарафыннан билгеләнә.

2 статья. Татарстан Республикасы халык депутатларының берләштерелгән Советы халык депутаты

Җирле Советлар берләшкән очракта әлеге Советларның халык депутатлары, үзләре сайланган чорга вәкаләтләре сакланган килеш, берләштерелгән Совет төзелгән көннән халык депутатларының берләштерелгән Советы халык депутаты статусына ия булалар. Бу вакытта берләштерелгән Совет халык депутаты сайлаучылары алдында җаваплы була һәм алар алдында хисап тота.

Әлеге Законның барлык нормалары да берләштерелгән Совет халык депутатына кагыла.

3 статья. Татарстан Республикасы халык депутатларының җирле Советы халык депутатының вәкаләтләре чоры

Татарстан Республикасы халык депутатларының җирле Советы халык депутатының вәкаләтләре, тиешле территория сайлау комиссиясенең сайланган халык депутатларын теркәү турындагы беркетмәсе тарафыннан расланып, аны җирле Совет халык депутаты итеп сайлаган көннән башлана һәм тиешле җирле Советның яңа чакырылыш халык депутатларын сайлаулар көненнән яисә аның вәкаләтләре вакытыннан алда туктатылган очракларда тәмамлана.

<u>4 статья.</u> Татарстан Республикасы халык депутатларының җирле Советы халык депутатының эшчәнлеге белән җитештерү һәм хезмәт вазифаларын үтәвенең бәйләнеше

Татарстан Республикасы халык депутатларының җирле Советы халык депутаты үз вәкаләтләрен, кагыйдә буларак, җитештерү яисә хезмәт эшчәнлегеннән аерылмыйча башкара.

Җирле Совет сессияләре, җирле Советның үзе сайланган органнары утырышлары, шулай ук җирле Совет һәм аның органнарының йөкләмәләрен үтәү вакытына халык депутатларының җирле Совет халык депутаты җитештерү яисә хезмәт вазифаларын үтәүдән азат ителә. Азат итү тәртибе халык депутатларының тиешле җирле Советы тарафыннан билгеләнә.

<u>5 статья.</u> Татарстан Республикасы халык депутатларының җирле Советы халык депутатының сайлаучылар белән үзара мөнәсәбәте

Татарстан Республикасы халык депутатларының җирле Советы халык депутаты үз сайлау округы сайлаучылары белән бәйләнештә тора.

Татарстан Республикасы халык депутатларының җирле Советы халык депутаты сайлаучылары алдында җаваплы һәм алар алдында хисап тота.

Татарстан Республикасы халык депутатларының җирле Советы халык депутаты округ сайлаучылары тарафыннан вәкаләтләре чоры беткәнчегә кадәр үк чакыртып алынырга мөмкин. Округ сайлаучылары тарафыннан халык депутатын чакыртып алу тәртибе Татарстан Республикасы законы нигезендә билгеләнә.

<u>6 статья.</u> Татарстан Республикасы халык депутатларының җирле Советлары халык депутатларының депутат төркемнәренә, депутат клубларына һәм башка ирекле депутат берләшмәләренә берләшү хокукы

Җирле Совет халык депутатлары даими һәм вакытлы депутат төркемнәренә, клубларга һәм башка ирекле депутат берләшмәләре-

нә берләшергә хаклы. Депутат берләшмәләрен төзү, аларның вәкаләтләре һәм теркәлү рәвеше җирле Совет регламенты тарафыннан билгеләнә.

<u>7 статья.</u> Депутат этикасы

Татарстан Республикасы халык депутатларының җирле Советы халык депутаты закон нормаларын, әдәп һәм этика кагыйдәләрен катгый үтәргә тиеш. Җирле Совет халык депутаты үзенең статусын гражданнар, җәмгыять һәм дәүләт мәнфәгатьләренә зыян китерерлек итеп файдаланырга тиеш түгел.

Депутат этикасын бозган очракта депутатның тәртибе хакындагы мәсьәлә тиешле җирле Совет кушуы буенча депутат этикасы мәсьәләләре комиссиясе яисә башка комиссия тарафыннан карала.

<u>8 статья.</u> Татарстан Республикасы халык депутатларының җирле Советы халык депутатының вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату

Татарстан Республикасы халык депутатларының җирле Советы халык депутатының вәкаләтләре тиешле җирле Совет карары нигезендә түбәндәге очракларда вакытыннан алда туктатыла:

- вәкаләтләрен туктатуы турында җирле Совет халык депутатының шәхси гаризасы нигезендә;
- җирле Совет халык депутаты булган затка карата гаепләү турындагы хөкем карары закон көченә кергәндә;
- җирле Совет халык депутаты тиешле Совет территориясендәге хезмәт эшчәнлеген өзеп, җирле Совет территориясеннән читтәге даими яшәү урынына күчеп киткәндә;
- җирле Совет халык депутаты җирле Совет халык депутаты вәкаләтләренә туры килмәүче эш урынын билгәндә;
- җирле Совет халык депутаты Татарстан Республикасы гражданлыгын югалткан очракта.

Татарстан Республикасы Законында билгеләнгән тәртиптә сайлаучылары вакытыннан элек чакыртып алганда, Татарстан Республикасы халык депутатларының җирле Советы халык депутатының вәкаләтләре туктатыла.

9 статья. Татарстан Республикасы халык депутатларының җирле Советы халык депутатының төп хокуклары

Халык депутатларының җирле Совет халык депутаты түбәндәгеләргә хаклы:

- тиешле дәүләт органнарына һәм урындагы затларга гарызнамә белән мөрәҗәгать итәргә;

- тиешле административ-территория берәмлеге территориясендә барлык дәүләт һәм җәмәгать органнарына, оештыру-хокукый һәм милек рәвешләренә карамастан, предприятиеләргә, учреждениеләргә, оешмаларга депутат эшчәнлеге мәсьәләләре буенча мөрәҗәгать итәргә һәм куелган мәсьәләләрне тикшергәндә катнашырга;

- Советлар эшендә катнашып, тиешле җирле Совет территориясендә дәүләт органнарының, оештыру-хокукый һәм милек рәвешләренә карамастан, предприятиеләрнең, учреждениеләрнең һәм оешмаларның эшен тикшереп торуны гамәлгә ашырырга;

- төрле депутат төркемнәренең, клубларының һәм башка ирекле депутат берләшмәләренең эшендә катнашырга;

- сайлаучылар белән җыелышлар һәм очрашулар үткәрергә.

## II бүлек

## Халык депутатларының җирле Советы халык депутатының Советтагы һәм аның органнарындагы эшчәнлеге

10 статья. Депутатның җирле Совет сессияләрендә катнашуы

Җирле Советларның сессияләрендә депутатлар коллектив, ирекле һәм эшлекле фикер алышу нигезендә дәүләт хакимиятенең тиешле вәкиллекле органы карамагындагы мөһим мәсьәләләрне карыйлар һәм хәл итәләр.

Халык депутаты Совет сессияләрендә һәм аларның үзе сайланган органнары утырышларында булырга һәм аларның эшендә катнашырга тиеш. Совет сессиясенә яисә аның органнары утырышына килә алмый калган очракта депутат бу турыда Совет президиумына яисә аның рәисенә, сәбәпләрен күрсәтеп, хәбәр итә.

11 статья. Җирле Совет халык депутатының җирле Совет сессияләрендәге вәкаләтләре

Халык депутатларының җирле Советы халык депутаты халык депутатларының җирле Советы сессиясендә каралучы барлык мәсьәләләр буенча хәлиткеч тавыш хокукыннан файдалана.

Җирле Совет халык депутаты түбәндәгеләргә хаклы:

тиешле җирле Совет органнарына сайларга һәм сайланырга;

Совет тарафыннан оештырылучы органнарның шәхси составы һәм халык депутатлары Советы тарафыннан сайланучы яисә килештерелүче урындагы зат кандидатуралары буенча фикерен белдерергә;

халык депутатлары Советы каравына мәсьәләләр тәкъдим итәргә;

Совет сессиясе көн тәртибе буенча, тикшерелүче мәсьәләләрне карау тәртибе һәм аларның асылы буенча тәкъдимнәр һәм кисәтүләр кертергә;

Совет сессиясендә тиешле җирле Совет алдында хисап тотарга яисә шушы җирле Совет тикшереп торырга тиешле теләсә кайсы органның яисә урындагы затның хисабын яки мәгълүматын тыңлау турында тәкъдим кертергә;

Совет тарафыннан сайланган хакимият башлыгына, урындагы затка ышанычсызлык белдерү турындагы мәсьәләне күтәрергә;

дәүләт һәм җәмәгать органнары, оештыру-хокукый һәм милек рәвешләренә карамастан, предприятиеләр, учреждениеләр һәм оешмалар тарафыннан Татарстан Республикасы территориясендә гамәлдә булган законнарның үтәлешен тикшерүнең зарурлыгы турында, халык депутатларының җирле Советы карамагындагы теләсә кайсы мәсьәлә буенча депутат тикшерүләре уздыру турында Совет сессиясенә һәм тиешле җирле Совет органына тәкъдимнәр кертергә;

фикер алышуларда катнашырга, гарызнамәләр белән мөрәҗәгать итәргә, нотыкчыларга, шулай ук утырышта рәислек итүчегә сораулар бирергә, җавап таләп итәргә һәм аларга бәя бирергә;

үз тәкъдимнәрен дәлилләп һәм тавыш бирү тәртипләре буенча чыгыш ясарга, белешмәләр бирергә; тикшерелүче мәсьәләләр буенча карар проектларын һәм аларга төзәтмәләр кертергә.

Фикер алышулар туктатылу сәбәпле, аларда катнашмаган җирле Совет халык депутаты рәислек итүчегә чыгышының текстын тап-

шырырга хаклы, чыгышның тексты тиешле Совет сессиясенең беркетмәсенә теркәлә;

Совет сессияләренең һәм аның органнарының беркетмәләрендә үз чыгышларының текстлары белән басылып чыкканчыга кадәр танышырга, шулай ук басылмый торган чыгышларының текстларын алырга.

Совет сессиясендә депутатлар керткән тәкъдимнәр һәм искәрмәләр карала, карарларны эшләп бетергәндә һәм кабул иткәндә исәпкә алына. Алар кире кагылган очракта депутатка язмача яисә телдән нигезләнгән җавап бирелә.

Совет яисә аның органнары карары белән килешмәгән халык депутаты сессиядә яисә утырышта үзгә фикерен җиткерү хокукына ия.

Җирле Совет халык депутаты законда тыелган гамәлләр кылмаса, Совет сессиясендәге яисә аның органнары утырышларындагы чыгышларында белдерелгән карашы өчен һәм каралучы мәсьәләләр буенча тавыш биргәндәге фикере өчен җаваплылыкка тартыла алмый.

Әлеге статьяда күрсәтелгән хокукларны гамәлгә ашыру тәртибе әлеге Закон, Татарстан Республикасының башка закон актлары, халык депутатларының тиешле җирле Советы регламенты тарафыннан билгеләнә.

<u>12 статья.</u> Депутат гарызнамәсе

Татарстан Республикасы халык депутатларының җирле Советы халык депутаты яисә халык депутатлары төркеме тиешле дәүләт идарәсе органнарына һәм урындагы затларга гарызнамә белән мөрәҗәгать итәргә хаклы.

Депутат гарызнамәсе язмача кертелә яисә телдән белдерелә. Язмача кертелгән гарызнамә Совет сессиясендә халык депутаты тарафыннан игълан ителә яисә аның үтенече буенча рәислек итүче тарафыннан белдерелә.

Гарызнамә мөрәҗәгать ителгән дәүләт органы яисә урындагы зат Совет сессиясендә гарызнамәгә телдән яисә язма җавап бирергә тиеш. Гарызнамәгә җавап Совет сессиясендә игълан ителә. Фикер алышу нәтиҗәләре буенча карар кабул ителә.

Гарызнамә, аңа җавап, халык депутатларының җирле Советы-

ның гарызнамәне карау нәтиҗәләре буенча кабул иткән карары матбугатта басылып чыга һәм хәбәр ителә.

13 статья. Җирле Советларның халык депутатлары тарафыннан Совет сессиясендә кертелгән тәкъдимнәрне һәм искәрмәләрне карау

Җирле Совет халык депутатларының сессияләрдә әйтелгән яисә рәислек итүчегә язма рәвештә тапшырылган тәкъдимнәре һәм искәрмәләре Совет, аның даими комиссияләре тарафыннан карала яисә карау өчен тиешле дәүләт органнарына, җәмәгать берләшмәләренә һәм урындагы затларга җибәрелә.

Депутатларның җирле Совет сессиясендә кертелгән тәкъдимнәре һәм искәрмәләре җибәрелгән дәүләт һәм җәмәгать органнары, шулай ук урындагы затлар аларны бер айдан да соңга калмыйча карарга тиеш, ә өстәмә өйрәнү һәм тикшерү таләп ителмәгән очракларда кичекмәстән каралырга һәм нәтиҗәләр турында депутатның үзенә, шулай ук Советның президиумына яисә рәисенә хәбәр ителергә тиеш.

Депутатларның тәкъдимнәрен һәм искәрмәләрен карауны һәм гамәлгә ашыруны халык депутатларының тиешле Советы органнары тикшереп тора.

14 статья. Җирле Совет халык депутатының Совет органнарындагы эшчәнлеге

Совет президиумы, Советның даими комиссиясе һәм башка органнары составына керүче җирле Совет халык депутаты аларның эшендә катнашырга тиеш.

Даими комиссия составына кермәүче җирле Совет халык депутаты аның утырышларында катнашырга, тәкъдимнәр кертергә, каралучы мәсьәләләр буенча фикер алышканда һәм карарлар кабул иткәндә киңәш бирү тавышы хокукы белән катнашырга хаклы.

Үзе кергән комиссиянең карары белән килешмәүче, шулай ук киңәш бирү тавышы хокукы белән катнашучы депутат Совет сессиясендә үз фикерен белдерергә яисә рәислек итүчегә ул хакта язмача хәбәр итәргә хаклы.

Халык депутаты президиум, даими комиссия эшендә даими рә-

вештә сәбәпсез катнашмаган өчен аларның составыннан чыгарылырга мөмкин.

15 статья. Җирле Совет халык депутатының дәүләт органнары, предприятиеләр, учреждениеләр һәм оешмалар эшен тикшерүдә катнашуы

Җирле Совет халык депутаты Совет яисә аның органнары кушуы буенча Совет территориясендә урнашкан дәүләт һәм җәмәгать органнарының, оештыру-хокукый һәм милек рәвешләренә карамастан, предприятиеләрнең, учреждениеләрнең һәм оешмаларның Совет карамагындагы мәсьәләләр буенча эшләрен тикшергәндә катнаша. Тикшерү нәтиҗәләре турында ул Советка яисә аның органнарына хәбәр итә, кирәк очракта күрсәтелгән кимчелекләрне бетерү, законсыз карарларны юкка чыгару, закон бозган һәм Совет карарларын үтәмәгән затларны җавапка тарту хакында тәкъдимнәр кертә.

## Ш бүлек

## Җирле Совет халык депутатының сайлау округындагы эшчәнлеге

16 статья. Җирле Совет халык депутатының сайлау округы эшенә бәйләнешле вәкаләтләре

Халык депутатларының җирле Советы халык депутаты сайлау округында үзенең вәкаләтләрен гамәлгә ашыру максатларында түбәндәгеләргә хаклы:

дәүләт хакимияте һәм идарәсе органнарында, тиешле җәмәгать берләшмәләрендә сайлаучылар мәнфәгатьләренә кагылышлы теләсә-кайсы мәсьәлә каралганда катнашырга;

Совет һәм аның органнары карарларының үтәлешен оештыруда һәм тикшереп торуда катнашырга;

үз инициативасы буенча, кирәк булса җәмәгатьчелекне һәм белгечләрне дә җәлеп итеп, законнарны, гражданнарның хокукларын һәм законлы ихтыяҗларын бозу турында мәгълүматларны, бюрократизм күренешләрен тикшерергә;

дәүләт һәм җәмәгать органнарына, оештыру-хокукый һәм милек рәвешләренә карамастан, предприятиеләргә, учреждениеләргә һәм оешмаларга үзләре җибәргән тәкъдимнәрне, гаризаларны һәм шикаятьләрне карауны тикшереп торуны гамәлгә ашырырга, аларны карaганда үзләре дә катнашырга. Дәүләт һәм җәмәгать органнарының, оештыру-хокукый һәм милек рәвешләренә карамастан, предприятиеләрнең, учреждениеләрнең һәм оешмаларның урындагы затлары халык депутатына аның тикшереп тору эшчәнлегендә ярдәм итәргә тиеш;

округ сайлаучылары белән җыелышлар, җәмәгать берләшмәләренең җирле органнары белән очрашулар үткәрергә;

халык депутатларының төрле берләшмәләре, җирле үзидарә органнары, эш (уку, хезмәт итү) урыны һәм яшәү урыны буенча җыелышлар эшендә катнашырга.

17 статья. Җирле Совет халык депутатының гражданнарның тәкъдимнәрен, гаризаларын һәм шикаятьләрен каравы

Җирле Совет халык депутаты үзенә килгән тәкъдимнәрне, гаризаларны һәм шикаятьләрне законнарда билгеләнгән тәртиптә карый, аларны дөрес итеп һәм вакытында хәл итү чараларын күрә;

гражданнарны кабул итә, җәмәгатьчелек фикерен өйрәнә, халык депутатларының җирле Советына һәм башка дәүләт органнарына тәкъдимнәр кертә.

18 статья. Татарстан Республикасы халык депутатларының җирле Советы халык депутатының сайлаучылар алдында хисабы

Җирле Совет халык депутаты елга кимендә бер тапкыр округ сайлаучылары яисә эш (уку, хезмәт итү) урыны һәм аны депутатлыкка кандидат итеп чыгарган җәмәгать берләшмәләре буенча сайлаучылар җыелышлары алдында үз эше турында, Советның тулаем һәм үзе сайланган органнарның эше хакында, сайлау алды программасы үтәлешенең барышы хакында хисап тота.

Җирле Совет халык депутатының хисабы округта яшәүче сайлаучылар санының кимендә ике процентыннан торган сайлаучылар

теркеме таләбе буенча да үткәрелергә мөмкин.

Дәүләт хакимияте һәм идарәсенең җирле органнары, җәмәгать берләшмәләре, массакүләм мәгълүмат чаралары урыннарда җирле Совет халык депутатының хисабы хакында халыкка хәбәр итәләр.

19 статья. Татарстан Республикасы халык депутатларының җирле Советы халык депутатына сайлаучылар алдында хисап тотканда һәм алар белән очрашулар үткәргәндә ярдәм итү

Җирле Совет халык депутатына округ сайлаучылары алдында хисап тотулар һәм алар белән очрашулар үткәрү өчен кирәкле шартлар тудырыла. Аның үтенече буенча халык депутатларының җирле Советы президиумы яисә тиешле җирле хакимият, оешты-ру-хокукый һәм милек рәвешләренә карамастан, предприятиеләр-нең, учреждениеләрнең һәм оешмаларның хакимиятләре бина бирә-ләр, гражданнарга депутатның хисап тоту, сайлаучылар белән оч-рашулар үткәрүенең вакыты һәм урыны турында хәбәр итәләр, ча-кырулар буенча очрашуларга үзләренең вәкилләрен җибәрәләр, башкача ярдәм күрсәтәләр.

Җирле Совет халык депутаты үтенече буенча дәүләт органна-ры, оештыру-хокукый һәм милек рәвешләренә карамастан, предпри-ятиеләр, учреждениеләр, оешмалар аңа хисап һәм чыгышлар өчен кирәкле белешмәләрне һәм мәгълүмат материалларын бирәләр.

## IV бүлек

## Депутат эшчәнлеге гарантияләре

20 статья. Татарстан Республикасы халык депутатларының җирле Советы халык депутатының урындагы зат-лар тарафыннан кичектергесез кабул ителү хо-кукы

Җирле Совет халык депутаты урындагы затлар тарафыннан де-путат эшчәнлеге мәсьәләләре буенча кичектергесез кабул ителү хокукыннан, шулай ук, депутат таныклыгын күрсәтеп, Совет тер-

риториясендәге барлык дәүләт һәм җәмәгать органнарына, оештыру-хокукый һәм милек рәвешләренә карамастан, предприятиеләргә, учреждениеләргә, оешмаларга тоткарлыксыз керү хокукыннан файдалана.

21 статья. Татарстан Республикасы халык депутатларының җирле Советы халык депутатының мөрәҗәгатьләрен карау буенча урындагы затларның вазифалары

Җирле Совет халык депутаты барлык дәүләт һәм җәмәгать органнарының, оештыру-хокукый һәм милек рәвешләренә карамастан, предприятиеләрнең, учреждениеләрнең һәм оешмаларның урындагы затларына депутат эшчәнлегенә бәйле мәсьәләләр буенча мөрәҗәгать итәргә һәм аларны караганда катнашырга хаклы.

Урындагы зат депутатның мөрәҗәгатенә кичектергесез җавап бирергә, ә кирәк чакта, бер айдан да соңга калмыйча, шушы мәсьәләне өстәмә рәвештә өйрәнергә яисә тикшерергә тиеш.

Җирле Совет халык депутатының халык депутатлары Советлары, аларның органнары һәм җирле хакимият вәкаләтләре карамагындагы мәсьәләләр буенча мөрәҗәгатьләрен шушы органнар карарга тиеш. Каралу көне турында депутатка алдан хәбәр ителергә тиеш.

22 статья. Татарстан Республикасы халык депутатларының җирле Советы халык депутатының закон бозуларны бетерүне таләп итү хокукы

Җирле Совет халык депутаты, дәүләт хакимияте вәкиле буларак, урыннарда закон бозуларны туктатуны таләп итәргә, ә кирәк очракларда гражданнарның хокукларын һәм законлы ихтыяҗларын бозуларны туктатуны таләп итеп, урындагы затларга мөрәҗәгать итәргә хаклы.

Җирле Совет халык депутатының таләбе мөрәҗәгать ителгән дәүләт һәм җәмәгать органнарының, оештыру-хокукый һәм милек рәвешләренә карамастан, предприятиеләрнең, учреждениеләрнең һәм оешмаларның урындагы затлары закон бозуларны бетерү өчен, ә кирәк очракта, бу хакта депутатка хәбәр итеп, гаепләне җа-

ваплылыкка тарту өчен чараларны кичектергесез күрергә тиеш.

Чаралар күрмәгән очракта урындагы затлар законда билгеләнгәнчә җаваплылыкка тартылалар.

23 статья. Татарстан Республикасы халык депутатларының җирле Советы халык депутатының мәгълүматлар һәм киңәшләр алу хокукы

Халык депутатлары Советы президиумы, тиешле җирле хакимият җирле Совет халык депутатын халык депутатларының җирле Советы тарафыннан кабул ителгән документлар белән, шулай ук хөкүмәт, дәүләт һәм җәмәгать органнары тарафыннан рәсми рәвештә таратылучы мәгълүмати һәм белешмә материаллар белән тәэмин итә.

Халык депутатлары Советы президиумы һәм тиешле җирле хакимият, Совет территориясендә урнашкан башка дәүләт һәм җәмәгать органнары, шулай ук урындагы затлар, җирле Совет халык депутаты мөрәҗәгать иткәндә, депутат эшчәнлеге белән бәйле мәсьәләләр буенча аны белгечләрнең киңәшләре белән тәэмин итәргә, кирәкле мәгълүматлар һәм документлар бирергә тиеш.

Җирле Совет халык депутаты дәүләт хакимияте һәм идарәсенең җирле органнары тарафыннан гамәлгә куелучы массакүләм мәгълүмат чаралары аша үзенең депутат эшчәнлеге мәсьәләләре буенча чыгыш ясау өчен өстенлекле хокукка ия. Депутат тарафыннан тәкъдим ителгән материалларны аның ризалыгыннан башка редакцияләү рөхсәт ителми.

24 статья. Татарстан Республикасы халык депутатларының җирле Советы халык депутатының намусын һәм абруен яклау

Җирле Совет халык депутатын хурлау, шулай ук аңа яла ягу законда билгеләнгәнчә җаваплылыкка китерә.

25 статья. Татарстан Республикасы халык депутатларының җирле Советы халык депутатының кагылгысызлыгы

Татарстан Республикасы халык депутатларының җирле Советы

халык депутаты үзенең барлык вәкаләтләре чорына кагылгысызлыкка ия була. Ул Татарстан Республикасы территориясендә тиешле җирле Совет рөхсәтеннән башка, җинаять кылу урынында тоткарлану очракларыннан гайре, хөкем итү тәртибендә билгеләнә торган җинаять җаваплылыгына яисә административ җаваплылыкка тартыла алмый, тоткарлана алмый, кулга алынмый, аңа тентү уздырылмый, шулай ук шәхси тикшерүгә җәлеп ителми, башка кешеләрнең иминлеген тәэмин итү өчен законда каралган очраклар моңа керми.

Җирле Совет халык депутатына карата җинаять эше район, шәһәр прокуроры, шулай ук Татарстан Республикасы Прокуроры тарафыннан кузгатылырга мөмкин.

Җирле Совет халык депутаты белдерелгән фикере, тавыш биргәндәге карашы өчен, шул исәптән аның вәкаләтләре чоры узгач та, җинаять җаваплылыгына тартыла алмый. Әлеге нигезләмә депутат тарафыннан законнарда җаваплылык каралган ачыктан-ачык хурлаулар яисә яла ягулар һәм башка хокук бозулар булган очракларга карамый.

Халык депутатының торак һәм хезмәт итү урыннары, багажы, шәхси һәм хезмәт транспорты чаралары, язышкан хатлары, ул файдалана торган элемтә чаралары, шулай ук аның документлары кагылгысызлыкка ия.

<u>26 статья.</u> Татарстан Республикасы халык депутатларының җирле Советы халык депутатын җаваплылыкка тарту өчен рөхсәт алу тәртибе

Җирле Совет халык депутатын, башка кешеләрнең иминлеген тәэмин итү өчен законда каралган башка очраклардан тыш, хөкем итү тәртибендә билгеләнә торган җинаять җаваплылыгына яисә административ җаваплылыкка тарту өчен, җинаять кылу урынында тоткарлау очракларыннан гайре, тоткарлау, кулга алу, тентү ясау өчен, шулай ук аңа шәхси тикшерү уздыру өчен Татарстан Республикасы халык депутатларының тиешле Советы ризалыгын алу йөзеннән, район (шәһәр) прокуроры халык депутатларының тиешле җирле Советына тәкъдим кертә. Ул Татарстан Республикасы Прокуроры тарафыннан да кертелергә мөмкин. Халык депутатларының тиешле җирле Советы прокурор тәкъдимен бер айдан да соңга калмыйча карый.

Кирәк чакта прокурордан өстәмә материаллар таләп итәлергә мөмкин. Җирле Совет халык депутатына кагылышлы мәсьәләләрне караганда, ул депутат үзе дә катнашырга хаклы. Халык депутатларының тиешле җирле Советы дәлилле карар кабул итә һәм өч көн эчендә бу хакта прокурорга хәбәр итә.

Әгәр прокурорның әлеге статьяда каралган тәртиптә кертелгән тәкъдиме Татарстан Республикасы халык депутатларының җирле Советы тарафыннан бер ай эчендә каралмаса, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тиешле яисә югарырак прокурорның тәкъдиме буенча аны кичекмәстән карауны тәэмин итү чараларын күрә.

Халык депутатларының җирле Советына тәкъдим керткән прокурор, эш тәмамланганнан соң өч көн эчендә, эшне тикшерү яки карау нәтиҗәләре хакында депутатны җаваплылыкка тарту яисә аны кулга алу өчен рөхсәт бирүче Советка хәбәр итәргә тиеш.

Халык депутатларының җирле Советы карары белән килешмәгәндә, Татарстан Республикасы Прокуроры җирле Совет карарын юкка чыгару турындагы тәкъдим белән Татарстан Республикасы Дәүләт Советына чыгарга хаклы.

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Татарстан Республикасы халык депутатларының җирле Советы карарын юкка чыгарырга яисә Татарстан Республикасы халык депутатларының җирле Советы карарына ризалык белдерергә хаклы. Әгәр Татарстан Республикасы халык депутатларының җирле Советы элекке карарны хупласа, мәсьәлә Татарстан Республикасы Прокуроры тәкъдиме буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан нигездә хәл итәлергә мөмкин.

Татарстан Республикасы халык депутатларының җирле Советы халык депутаты Татарстан Республикасы территориясеннән читтә җинаять кылган яисә административ хокук бозган булса, аны хөкем тәртибендә билгеләнүче җинаять җаваплылыгына тарту, кулга алу өчен яисә аңа карата административ җәза чаралары куллану өчен ризалык алу таләп ителми.

27 статья. Татарстан Республикасы халык депутатларының җирле Советы халык депутатының хезмәт хокуклары гарантияләре

Татарстан Республикасы халык депутатларының җирле Советы халык депутаты, Татарстан Республикасы халык депутатларының тиешле Советы ризалыгыннан башка, хакимият инициативасы белән, оештыру-хокукый һәм милек рәвешләренә карамастан, предприятиедән, учреждениедән яисә оешмадан эштән азат ителә алмый, уку йортыннан чыгарыла алмый.

Эчке эшләр органнары хезмәткәрләре, хәрби хезмәткәрләр һәм хезмәтләре уставлар, нигезләмәләр тарафыннан җайга салына торган башка категорияләрдәге гражданнар арасыннан сайланган җирле Совет халык депутаты, Совет ризалыгыннан башка, хакимият яисә тиешле эчке эшләр органы җитәкчесе инициативасы белән хезмәттән азат ителә алмый, түбәнрәк хезмәт урынына куела алмый, званиесе буенча төшерелә алмый, шулай ук хезмәт урыны буенча күчерелә алмый. Аңа эш урыны буенча чираттагы махсус звание бирү тоткарланырга тиеш түгел. Депутат вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен җитештерү һәм хезмәт вазифаларыннан азат ителгән җирле Совет халык депутатына вәкаләтләр чоры тәмамланганнан соң элеккеге эше (хезмәт урыны) тәкъдим ителә, ә ул булмаганда - шул ук яисә, оештыру-хокукый һәм милек рәвешләренә карамастан, башка предприятиедә, учреждениедә яки оешмада аның ризалыгы белән элеккегесенә тиң башка эш (хезмәт урыны) тәкъдим ителә.

Халык депутатының җирле Советта яисә аның органнарында төп эшеннән азат ителеп эшләгән вакыты гомуми һәм өзлексез эш (хезмәт) стажына, белгечлек буенча эш (хезмәт) стажына, озак еллар хезмәт иткән өчен (әлеге предприятиедә белгечлеге буенча эш (хезмәт) стажы өчен) хезмәт хакына процентлы өстәмәләрне, өстәмәләрнең һәм ташламаларның барлык төрләрен билгеләргә һәм бер мәртәбә бирелә торган акчалата түләү һәм озак еллар хезмәт иткән өчен процентлы өстәмә алырга хокук бирүче эш (хезмәт) стажына, шулай ук ташламалы шартларда ташламалы күләмнәрдә пенсия алырга (депутат әлеге ташламалар каралган эш урыныннан сайланган булса) хокук бирүче эш (хезмәт) стажына кертеп санала.

28 статья. Татарстан Республикасы халык депутатларының җирле Советы халык депутатының транспортта бушлай йөрү хокукы

Татарстан Республикасы халык депутатларының район Советы халык депутаты - район территориясендә, шәһәрдәге район, шәһәр Советы депутаты - шәһәр территориясендә, ә халык депутатларының берләштерелгән Совет халык депутаты район һәм шәһәр территориясендә республика буйсынуындагы автомобиль һәм су транспортында, шулай ук, таксилардан гайре, шәһәр пассажир транспортының барлык төрләрендә дә, ә район шәһәр Советы депутаты шәһәр яны транспортында бушлай йөрү хокукыннан файдаланалар.

29 статья. Татарстан Республикасы халык депутатларының җирле Советы халык депутатының депутат таныклыгы һәм күкрәк тамгасы

Җирле Совет халык депутатына депутат таныклыгы һәм күкрәк тамгасы бирелә, ул алардан вәкаләтләре чоры буена файдалана.

Җирле Совет халык депутатының таныклыгы һәм күкрәк тамгасы турындагы нигезләмәләр, аларның үрнәкләре һәм тасвирламалары Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан раслана.

30 статья. Урындагы затларның әлеге Закон таләпләрен үтәмәгән өчен җаваплылыгы

Дәүләт хакимияте һәм идарәсе органнарының, җирле үзидарә органнарының, оештыру-хокукый һәм милек рәвешләренә карамастан, предприятиеләрнең, учреждениеләрнең, оешмаларның, җәмәгать берләшмәләренең урындагы затлары тарафыннан җирле Совет халык депутатының законлы таләпләре үтәлмәгәндә яисә депутат эшчәнлеген гамәлгә ашыруда аңа тоткарлыклар тудырылганда, шулай ук аңа белә торып ялган мәгълүматлар бирелгәндә яисә халык депутатына мәгълүматлар бирүнең һәм аның гарызнамәләренә, мөрәҗәгатьләренә җавап бирүнең әлеге законнарда билгеләнгән вакытлары һәм тәртибе үтәлмәгәндә, депутат эшчәнлеге гарантияләре бозылганда законда каралган җаваплылык билгеләнә.

31 статья. Татарстан Республикасы халык депутатларының җирле Советы халык депутатын үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен матди-финанс шартлар белән тәэмин итү

Җирле Совет сессияләре чорында, шулай ук депутат вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен әлеге Законда каралган башка очракларда халык депутаты җитештерү яисә хезмәт вазифаларын үтәүдән азат ителгән җирле Совет халык депутатына аның депутат эшчәнлегенә бәйле чыгымнары тиешле җирле Совет хисабыннан каплана.

Җирле Совет халык депутатын үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен матди-финанс шартлар белән тәэмин итү Татарстан Республикасы Дәүләт Советы раслаган Нигезләмә тарафыннан җайга салына".

2 статья. Әлеге Закон басылып чыккан көненнән үз көченә керә. 25 статьяның 1 өлешендәге һәм 26 статьяның 1 өлешендәге тоткарлау һәм тентү үткәрү турындагы нигезләмәләр Татарстан Республикасы Конституциясенә тиешле үзгәрешләр керткәннән соң үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты М.Шәймиев

Казан шәһәре,
1996 елның 30 мае
N 613